ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

# «Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1021307-7 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның $26^4$ статьясындагы 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына беренче укылышта кабул ителгән «Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1021307-7 номерлы федераль закон проектына төзәтмә кертергә.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы тору комитетына җибәрергә.
3. Күрсәтелгән төзәтмәне Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан рәсми вәкил итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Илдар Ирек улы Гыйльметдиновны билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2020 елның 26 ноябре
№ 722-VI ДС